Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

18 ноябрь 2022 ел № 3

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Югары Ырга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан,балачактан инвалид, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм алырның гаиләләреннән гайре ) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен төзекләндерү
- Югары Ырга авылында юлларны төзекләндерү
- Яңа Ырга авылында юлларны кышкы карап тоту;
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт; Югары Ырга авылы, Муса Җәлил урамы, 18 йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов